**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Зеленодольск районының аерым территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында**

Йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү очрагы ачыклану һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2006 елның 27 мартындагы 90 номерлы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск районы Большие Ключи авылының Волостнов урамында урнашкан «Залесный» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең кошчылык предприятиесе территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы вирусы барлыкка килүгә бәйле рәвештә, аларны бетерү турында карар кабул ителгәнгә кадәр, чикләү чараларын (карантин) кертергә.

2. Әлеге Указның 1 пункты нигезендә билгеләнгән Татарстан Республикасының аерым территориясендә кош, кошчылык продуктларын, азык һәм азыкка өстәмәләрнең әйләнешенә чикләүләрнең кушымтада бирелүче исемлеген, аларны бетерү турында карар кабул ителгәнгә кадәр, расларга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) әлеге Указның 1 пункты нигезендә билгеләнгән Татарстан Республикасының аерым территориясе чикләрендә (алга таба – имин булмаган пункт) эпизоотия чыганагын;

б) имин булмаган пункт чикләреннән 5 км радиустагы территория чикләрендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск районының Большие Ключи авылын, Светлое Озеро поселогын, Ивановский авылын, Соловьевка авылын, Каратмән авылын, Олы Җәке авылын, Олы Карагуҗа авылын, Кече Карагуҗа авылын, Кызыл Кармыш авылын кертеп, куркыныч янау зонасын;

в) имин булмаган пунктлар чикләреннән 10 км радиустагы территория чикләрендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск районының Бишнә

авылын, Олы Күлбаш авылын, Синтәк авылын, Чирүчи авылын, Уразлы авылын, Никольский авылын, Малые Ключи авылын, Маевка авылын, Бело-Безводный авылын, Садовый поселогын, Местечко Раифа поселогын, Үтәнгеш авылын кертеп, күзәтү зонасын.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йогышлылыгы югары булган кош гриппы вирусы чыганагын бетерү һәм авыру чыганагының Татарстан Республикасы территориясендә таралуын булдырмау буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 09 ноябрь
№ ПУ-734

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның «09» ноябрендәге
ПУ-734 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасының аерым территориясендә кош, кошчылык продуктлары, азык һәм азыкка өстәмәләр әйләнешенә кертелгән чикләүләр исемлеге**

Чикләү чаралары (карантин) гамәле вакытында имин булмаган пункт территориясендә:

территориягә чит кешеләр керүне һәм транспорт керүне туктатырга;

турыдан-туры хезмәт күрсәтүче персоналдан һәм чаралар уздырыла торган вакытка өстәмә рәвештә объектка беркетелгән ветеринария өлкәсендәге хезмәткәрләр һәм белгечләрдән тыш, имин булмаган пунктка чит кешеләр керүне тыярга;

кошларның имин булмаган төркеменә хезмәт күрсәтүче персоналның оешма территориясе буйлап йөрүен чикләргә, аларның башка кошлар һәм аларга хезмәт күрсәтүче затлар белән аралашуын булдырмаска;

чир йоктырган кошларны кан чыгармыйча юк итүне, үлгән һәм юк ителгән кошларны герметик тарага җыюны оештырырга;

кан чыгармыйча массачыл төстә кошларны юк итү вакытында, авыру тудыручы дип күздә тотылган чыганакның әйләнә-тирә мохиттә таралуын булдырмау шартларында, үләксәләрне күмүне билгеләнгән тәртиптә уздырырга;

имин булмаган пункт эчендә кошларны күчерүне һәм алардан кошларны, йомыркаларны һәм башка кошчылык продуктларын, шулай ук кош азыгы, эш коралларын, җиһазларны, кош тизәген чыгаруны туктатырга;

йорт кошлары булган башка хуҗалыкларга керүне, кошларны һәм кошчылык продуктларын, эш коралларын, җиһазларны, кош тизәген чыгаруны туктатырга;

имин булмаган пункт чигеннән кошларны чыгаруны һәм аларны башкача файдалануны туктатырга;

кош сатуны вакытлыча туктатырга;

имин булмаган пункттан чыгу юлларын (сукмакларны) ябарга, кирәкле санда дезинфекцияләү киртәләре, кием-салымны эшкәртү өчен пароформалин камералары һәм дезинфекцияләү җайланмалары белән җиһазландырылган тәүлек әйләнәсе кизү торачак контроль-үткәрү постлары куярга, аларда эшләргә ветеринария инспекторларын һәм хокук саклау органнары хезмәткәрләрен җәлеп итәргә;

карантин зонасында транспорт хәрәкәтен чикләргә, шул исәптән керү рөхсәт ителгән транспорт карантин зонасына узганда һәм аннан чыкканда мәҗбүри дезинфекцияләнергә тиеш;

авыруларга аеручa бирешүчән баш санын сую һәм юкка чыгару буенча чаралар уздырырга.